МИНИСТЕРСТВО
ЗЕМЕЛЬНЫХ И
ИМУЩЕСТВЕННЫХ
ОТНОШЕНИЙ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ
МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ
МИНИСТРЛЫГЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

19.09.2013 Казан ш. № 2898-р

**Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен Татарстан Республикасы Дәүләт милке реестрына кертү һәм аннан мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында**

1. Тәкъдим ителгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен Татарстан Республикасы Дәүләт милке реестрына кертү һәм аннан мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын (алга таба – Регламент) расларга.

2. Министр урынбасарларына, идарә башлыкларына хезмәткәрләрне Регламент белән таныштыруны оештырырга һәм аның тайпылышсыз үтәлешен тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен һәм юридик затларны Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте реестрына кертүнең административ регламентын раслау турында” 29.12.2007 N 2751-р карарын көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның башкарылуын контрольдә тотуны министр урынбасары Р.И.Шамеевка йөкләргә.

Министр
А.К.ХАМАЕВ

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
19 сентябрь 2013 ел N 2898-р
карары белән расланды

# Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен Татарстан Республикасы Дәүләт милке реестрына кертү һәм аннан мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрына кертү һәм аннан мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәтен күрсәтү) стандартларын һәм тәртибен билгели.

1.2. Дәүләт хезмәтен алучылар (алга таба – гариза бирүчеләр):

юридик затлар - Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрына кертү буенча дәүләт хезмәтен тормышка ашырганда;

юридик һәм физик затлар - Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрыннан мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәтен тормышка ашырганда

1.3. Дәүләт хезмәтен Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – Министрлык) күрсәтә.

1.3.1. Министрлыкның урнашкан урыны: Казан ш., Вишневский ур., 26 й.

Министрлыкның эш графигы: шимбә һәм якшәмбедән кала көн саен, дүшәмбе – пәнҗешәмбе – 9.00дән 18.00гә кадәр, җомга – 9.00дән 16.45кә кадәр, төшке аш 11.45тән 12.30га кадәр.

Җәмәгать транспортында:

№ 1, 4, 25, 43, 69 номерлы автобуслар белән “Калинин” тукталышына кадәр барырга;

метро станциясе – “Сукно бистәсе”.

1.3.2. Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының Учет, мониторинг һәм мәгълүмати арадашлык идарәсенең ТР Дәүләт милке реестры бүлегенең (алга таба – Бүлек) белешмә телефоны: 221-40-50.

1.3.3. Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайты адресы: http://mzio.tatarstan.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүматны түбәндәгечә алып була:

1) Министрлыкның гариза бирүчеләр белән эшләү өчен билгеләнгән бүлмәләренә урнаштырылган дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст рәвешендәге мәгълүматны эченә алган мәгълүмат стендларыннан;

2) «Интернет» ярдәмендә:

Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтыннан (алга таба – рәсми сайт) (http://mzio.tatarstan.ru);

Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.tatar.ru);

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать итеп (шәхсән яки телефоннан);

4) Министрлыкка язмача (шул исәптән, электрон документ формасында) мөрәҗәгать итеп.

1.3.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү мәсьәләләре турында мәгълүмат Бүлек белгече тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтына һәм Министрлыкның гариза бирүчеләр белән эшләү бүлмәләрендәге мәгълүмат стендларына урнаштырыла.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә хәл ителә:

Россия Федерациясе Конституциясе (РФ Законнары җыелмасы, 26.01.2009, N 4, ст. 445);

Россия Федерациясе Гражданлык кодексы (беренче кисәк) (алга таба – РФ ГК 1 к.) (РФ законнары җыелмасы, 05.12.1994, № 32, 3301 ст.);

“Күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-биреш итүгә хокукларны дәүләт теркәвенә алу турында” 21.07.1997, № 122-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 122-ФЗ Федераль закон) (РФ законнары җыелмасы, 28.07.1997, № 30, ст. 3594);

“Күчемсез мөлкәтнең дәүләт кадастры турында” 24.07.2007, № 221-ФЗ Федераль закон (РФ законнары җыелмасы, 30.07.2007, № 31, 4017 ст.);

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында” 27.07.2010 ел, № 210-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 210-ФЗ Федераль закон) (РФ законнары җыелмасы, 02.08.2010 ел, № 31, 4179 ст.);

Татарстан Республикасы Конституциясе (Республика Татарстан, N 87-88, 30.04.2002);

«Татарстан Республикасы милке белән идарә итү һәм эш итү турында» 2007 елның 26 июлендәге № 35-ЗРТ Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 7, 621 б.);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 05.12.2005 № 563 карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты – Татарстан Республикасы Хөкүмәте Регламенты («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2005, № 47-48, 985 б.,

Татарстан Республикасы дәүләт милке реестры турында нигезләмә (алга таба – ТР МК Карары № 150), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы дәүләт милке реестры турында нигезләмәне раслау хакында” 20.03.2003 N 150 Карары белән расланган (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы, апрель 2003, N 7, стр. 91);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы милке турындагы мәгълүматны ачу турында нигезләмәне раслау хакында» 16.05.2008 № 327 карары белән расланган (алга таба – ТР МК карары № 327) Татарстан Республикасы милке турындагы мәгълүматны ачу турында нигезләмә;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре” 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы” журналы, 2007, №37, 1379 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы | Стандартка таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте атамасы | Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрына кертү (алга таба – Реестр) һәм аннан мәгълүмат бирү | ст. 4 Закона РТ N 35-ЗРТ; Постановление КМ РТ N 407; Постановление КМ РТ N 150; Постановление КМ РТ N 327 |
| 2.2. Башкарма хакимиятнең дәүләт хезмәтен турыдан-туры | Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – Министрлык) | п. 3.3.7 Положения о Министерстве |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтүче органы атамасы | | |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе тасвирламасы | Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен Реестрга кертү;<br>Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен Реестрга кертүдән баш тарту;<br>Реестрдан өземтә;<br>Учет объектларының Реестрда булуы турында мәгълүмат юллау;<br>Учет объектларының Реестрда булмавы турында мәгълүмат юллау;<br>Реестрдан мәгълүмат бирүдән баш тарту | ст. 4 Закона РТ N 35-ЗРТ;<br>ТР МК карары № 407;<br>ТР МК карары № 150<br>ТР МК карары № 327 |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы | Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен Реестрга кертү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтү гариза бирелгәннән соң 25 көн эчендә башкарыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү туктатылып торса, гариза бирүче өстәмә белешмәләрк итергәннән 25 көн эчендә күрсәтелә.<br>Реестрдан мәгълүмат буенча дәүләт хезмәтен күрсәтү мөрәҗәгать кергәннән соң 21 көн эчендә һәм Региональ ведомоствоара электрон үзара арадашлык системасында катнашучыдан запрос кергәннән соң 5 эш көне эчендә башкарыла. | ТР МК карары № 150<br>ТР МК карары № 327 |
| 2.5. Дәүләт хезмәте, шулай ук гариза бирүчегә күрсәтелергә тиешле дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен | Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен Реестрга кертү өчен гариза бирүче түбәндәгеләрне тапшыра:<br>1. Юридик затның җитәкчесе имзалаган гариза.<br>Гаризага теркәлә:<br>- юридик затта булган дәүләт милкен учетка алу картасы (мөлкәтне юридик затка беркетү турында Министрлык карарын күрсәтеп,<br>мөлкәтне төрле хокукларда юридик | ТР МК карары № 150 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| закон яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге | затка беркетү турында шартнамәләр (өстәмә килешүләр) һәм юридик затка дәүләт мөлкәтен тапшыру-кабул итеп алу турында тиешле актлар) (юридик затта булган дәүләт мөлкәтенең учет картасы кәгазь форматта да, Министрлык билгеләгән күчергечтә электрон форматта да тапшырыла);<br>- соңгы бухгалтер отчеты датасына юридик затта булган Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте исемлеге (кәгазь форматта да, Министрлык билгеләгән күчергечтә).<br>2. Юридик затның устав күчермәсе.<br>3. Юридик затның уставының яңа редакциясе яки Уставка үзгәрешләр күчермәсе (булса).<br>Реестрдан мәгълүмат алу өчен гариза бирүче запрос юллый | | |
| 2.6. Норматив хокукый актларга туры китереп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган, дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм башка оешмаларда сакланган, гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге | Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен Реестрга кертү өчен Бердәм ведомствоара электрон үзара арадашлык системасы аша алына:<br>1. Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр.<br>2. Юридик затның салым органнарында учетка куелуы турында белешмә.<br>3. Юридик затка учет коды бирелүе турында дәүләт статистикасы органнарыннан белешмәләр.<br>4. Күчемсез мөлкәткә кадастр паспортлары күчермәләре (булса).<br>5. Күчемсез милеккә хокуклар һәм аның белән алыш-бирешкә хокуклар бердәм дәүләт реестрыннан өземтә яисә Күчемсез милеккә хокуклар һәм аның белән алыш-бирешкә хокуклар бердәм дәүләт реестрында соралган белешмә | | |

| | | |
|---|---|---|
| | булмавы турында белдерү | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен таләп ителгән һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүче башкарма орган тарафыннан тормышка ашырыла торган норматив-хокукый актларда каралган очракларда килештерү зарури булган дәүләт хакимияте органнары һәм аларның структур бүлекчәләре исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен килештерүләр таләп ителми. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләрнең тулы исемлеге | 1. Гариза белән әлеге Регламентның тиеш булмаган затның мөрәҗәгате (гариза бирүче үзе мөрәҗәгать иткәндә).<br>2. Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның тулы комплекты бирелмәгән.<br>3. Электрон докуиентлар белән кәгазь документларның туры килмәве | ТР МК карары № 150 |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен | Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен реестрга кертү процедурасын туктатып тору өчен нигезләр:<br>1. Бирелгән мәгълүматның Реестрда күренгән мәгълүмат белән чагышмавы.<br>2. Бирелгән мәгълүматның хокук билгеләүче документлардагы | ТР МК карары № 150<br>ТР МК карары № 327 |

| | | |
|---|---|---|
| нигезләрнең тулы исемлеге | мәгълүмат белән туры килмәве.<br>3. Бирелгән мәгълүматның ведмоствоара арадашлык аша алынган мәгълүматка туры килмәве.<br>Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен реестрга кертүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:<br>1. Мөлкәтнең Татарстан Республикасы милке булмавы ачыкланган.<br>2. Юридик затта Татарстан Республикасы милке булмавы ачыкланган.<br>3. Гариза бирүче учет объектын Реестрга кертү процедурасы туктатылганнан соң 30 көн эчендә өстәмә белешмә китермәгән.<br>4. Тапшырылган материаллар ТР МК Карары № 150, 20.03.2003 белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт милке реестры турында нигезләмә белән билгеләнгән таләпләргә туры килми.<br>Реестрдан мәгълүмат бирүдән баш тарту өчен түбәндгеләр нигез булып тора:<br>1. Мөрәҗәгатьтә законнар буенча үтеп керү чикләнгән мәгълүмат булган белешмә сорала.<br>2. Запросның эчтәлеге буенча гариза бирүчене кызыксындырган мәгълүмат кирәк булган кайсы объект турында сүз барганын тәгаенләп булмый.<br>3. Мөрәҗәгатьтә Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрында белешмә булмаган мөлкәт объекты күрсәтелгән | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәткән | Дәүләт хезмәте бушлай күрсәтелә | РФ ГК;<br>ТР МК карары № 150 |

| | | |
|---|---|---|
| өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төрле түләүнең тәртибе, күләме һәм алу нигезләре | | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булып торучы алынучы түләүләрнең тәртибе, күләме һәм нигезләре, андый түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп | Зарури һәм мәҗбүри хезмәт күрсәтү таләп ителми. | РФ ГК |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында запрос биргәндә һәм андый хезмәтләрне күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь срогы | Дәүләт хезмәте алучының (гариза бирүченең) кабул итүне (хезмәт күрсәтүне) көтүенең һәм дәүләт хезмәте күрсәтелү нәтиҗәсен алуның максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Дәүләт хезмәтен алучыларның аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне сорап | Гариза һәм документлар кергән көндә | |

| | | |
|---|---|---|
| гариза бирүченең запросын рәсмиләштерү срогы | | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә таләпләр | Гариза (запрос) Министрлыкка 420043, Казан ш., Вишневский ур., 26 й. адресы буенча бирелә (юллана).<br>Дәүләт хезмәтләре күрсәтелү тиешле күрсәткечләр белән җиһазланган бүлмәләрдә башкарыла.<br>һаваны суыту-җылыту системасы; янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы;<br>документлар тутыру өчен җиһаз;<br>Татарстан Республикасы Дәүләт интеграцияләнгән телекоммуникация системасына тоташтырылган мәгълүмати киоск;<br>мәгълүмати стенд.<br>Дәүләт хезмәте күп функцияләр башкаручы үзәктә күрсәтелми. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре | Дәүләт хезмәтенең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>- документларны кабул итү һәм карау срогының саклануы;<br>- Регламентның дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан бозылуын күрсәткән очракларның (нигезләнгән шикаятьләрнең) булуы (очраклар, шикаятьләр санының хезмәт күрсәтүче Министрлык белгечләренең гомуми санына чагыштырмасы).<br>Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>- Министрлык биналарының җәмгать транспортына якын булуы;<br>- кирәк кадәр санда белгечләрнең, шулай ук, гариза бирүчеләрнең | |

| | | |
|---|---|---|
| | документларын кабул итә торган урыннарның булуы;<br>- мәгълүмати стендларда һәм Интернет челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталында дәүләт хезмәте күрсәтүнең ысуллары, тәртибе һәм вакыты турында тулы мәгълүмат булу | |
| 2.16. Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Дәүләт хезмәте электрон формада күрсәтелми | |

3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларның (гамәлләрнең) электрон рәвештә үтәлүе үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә гамәлләр эзлеклелегенең тасвирламасы.

3.1.1. Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрына кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү;

2) гаризаны һәм аңа беркетелгән документларны кабул итү һәм регистрация;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запрослар формалаштыру һәм юллау;

4) Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрына кертү яки Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрына кертүдән баш тарту;

5) гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен җибәрү.

3.1.2. Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрына кертү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы 7 нче кушымтада китерелә.

3.1.3. Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрыннан мәгълүмат бирү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультация бирү;

2) запросны кабул итү һәм регистрация;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запрослар формалаштыру һәм юллау;

4) Реестрдан өземтә формасында мәгълүмат яисә Реестрда мөлкәт объектларының булуы (булмавы) турында белешмә, Реестрдан соралган мәгълүматны бирүдән баш тарту әзерләү;

5) Гариза бирүчегә Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрыннан мәгълүмат юллау, яисә Реестрдан соралган мәгълүматны бирүдән баш тарту турында хат юллау.

3.1.4. Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрыннан мәгълүмат бирү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы 7 нче кушымтада китерелә.

3.1.5. Региональ ведомствоара электрон үзара арадашлык системасы кысаларында Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрыннан мәгълүмат бирү түбәндәгеләрне процедураларны үз эченә ала:

1) запросны кабул итү;

2) Реестрдан өземтә яки Реестрда булу турында белешмәне яисә соралган мәгълүматны бирү турында электрон формада юллау.

3.1.6. Региональ ведомствоара электрон үзара арадашлык системасы кысаларында Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрыннан мәгълүмат бирү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы 8 нче кушымтада китерелә.

3.2. Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрына кертү

3.2.1. Гариза бирүчегә консультация бирү

Гариза бирүче, дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен, Бүлеккә шәхсән үзе, телефоннан, һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итүгә хокуклы.

Бүлек белгече гариза бирүчегә консультация бирә, шул исәптән тапшырылырга тиешле документларның составы, формасы ягыннан һәм дәүләт хезмәте алуга карата башка мәсьәләләр буенча, гариза бирүчегә ярдәм итә. Гариза бирүчегә кирәкле документлар тутыру буенча ярдәм күрсәтү соралмый.

Әлеге пункт билгели торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: биреләсе документациянең составы, формасы һәм эчтәлеге буенча консультация.

3.2.2. Гаризаны һәм аңа беркетелгән кабул итү һәм регистрацияләү

3.2.2.1. Гариза бирүче (вәкиле) әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар беркетелгән гаризасын Бүлеккә бирә яисә күрсәтелгән документларны почта аша юллый.

3.2.2.2. Бүлек белгече гариза һәм беркетелгән документлар Бүлеккә тапшырылса:

гариза һәм документларны кабул итә;

гариза бирүченең шәхесен ачыклый, шәхесне ачыклый торган документны тикшерә; вәкилнең вәкаләтләрен (боерык, ышанычнамә һ.б.) тикшерә;

әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документларның булу-булмавын тикшерә, түбәндәгеләрне ачыклый:

- документлар расланган, мөһер сугылган, законнарда билгеләнгән вазыйфаи затларның имзасы бар;

- документларның тексты танырлык итеп язылган, юридик зат атамалары кыскартмыйча бирелгән, урнашкан урыны күрсәтелгән;

- документларда чистартылган, өстәп язылган урыннар юк, сүзләр сызылмаган, алдан килештерелмәгән төзәтүләр кертелмәгән;

- документлар карандаш белән тутырылмаган;

- документларда аларның эчтәлеген төрлечә аңларга мөмкинлек бирә торган зарарланган урыннар юк.

Гариза бирүченең документ күчермәләре расланмаган булса, әлеге күчермәләр тапшырылганда төп нөсхә дә күрсәтелә һәм алар Бүлек белгече тарафыннан раслана.

Гариза бирүче документларның тулы комплектын тапшырмаса, шулай ук, техник хаталар булса яки алда күрсәтелгән таләпләргә туры китереп формалаштырылмаса, Бүлек белгече дәүләт хезмәтен гамәлгә ашыру өчен каршылыклар булуын хәбәр итә, тапшырылган документларда ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, документларда кире кайтара.

Бүлек белгече бирелгән документларәлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килсә, түбәндәгеләрне башкара:

гариза бирүчеләрнең учет кенәгәсенә документлар кабул ителү яки кабул итүдән баш тарту турында язу (язуның тәртип номеры, кабул итү датусы һәм минутына кадәр төгәл вакыты, документларның гомуми саны, гариза бирүче турында мәгълүмат, гариза бирүченең мөрәҗәгать максаты, документлар кабул итүдән баш тарту максаты, фамилия һәм инициалы);

гаризага беркетелгән документларның исемлеген тутыру, анда документларны кабул иткән һәм гариза бирүчеләрнең исәбен алып баручы кенәгәне тутыручы белгечнең фамилиясе һәм инициаллары күрсәтелә;

гаризага беркетелгән документларның исемлегенең бер данәсен гариза бирүчегә тапшыру;

Гаризаны кергән документлар белән, гаризага беркетелгән документларның исемлегенең бер данәсе белән регистрацияләү өчен Министрлыкның эш башкару һәм контроль бүлегенә (алга таба – эш башкару бүлеге) юллау.

Әлеге пунктта билгеләнелә торган процедуралар гариза һәм документлар кергән көнне үтәлә.

Процедураның нәтиҗәсе: тикшерелгән һәм эш башкару бүлегенә юлланган гариза һәм документлар; документларны кабул итүдән баш тарту.

3.2.2.3. Эш башкару бүлеге белгече гаризаны һәм аңа беркетелгән документларны алганнан соң, шулай ук, алар почта аша керсә дә, гаризаны һәм

документларны регистрацияли, керү номеры суга һәм карау өчен Бүлеккә юллый.

Әлеге пунктта билгеләнелә торган процедуралар гариза һәм документлар кергән көнне үтәлә.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм Бүлеккә юлланган гариза һәм аңа беркетелгән документлар.

3.2.3. Ведомствоара запрослар формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашкан органнарга юллау;

3.2.3.1. Бүлек белгече мөрәҗәгатьне алгач, мәгълүматны тәгаенләү өчен ведомствоара электрон арадашлык системасы аша электрон формада түбәндәге запросларны юллый:

гариза бирүче булып торган оешма - юридик зат турында белешмә бирү турында, ТР буенча ФСХИдан;

юридик затка учет коды бирү турында белешмә бирү турында Дәүләт статистикасы федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органына (алга таба – Татарстанстат);

аерым затның үзендәге күчемсез милек объектларына хокуклары турында ЕГРНнан өземтә бирү турында Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасындагы идарәсенә (алга таба - ТР буенча Росреестр);

Күчемсез милек объектларына кадастр паспортын бирү турында “Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең федераль кадастр палатасы” федераль дәүләт бюджетного учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына (алга таба – ТР буенча "ФКП Росреестр" ФБГУ филиалы);

Әлеге пункт билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң ике көн эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: белешмәләр (документлар) бирү турындагы запрослар.

3.2.4. Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен Реестрга кертү яки Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен Реестрга кертүдән баш тарту;

3.2.4.1. Бүлек белгече әлеге Регламентның 3.2.3.1 пунктына туры китереп юлланган запросларга ТР буенча ФСХИдан, Татарстанстат ТР буенча Росреестрдан, ТР буенча "ФКП Росреестр" ФБГУ филиалыннан соралган белешмәләр алынгач документларны карап чыга, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарта торган Регламентның 2.9 пунктында күрсәтелгән нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарта нигезләре булмаса, Бүлек белгече түбәндәгеләрне тормышка ашыра:

- электрон күчергечтә тапшырылган мәгълүматны Министрлыкның мәгълүмати системасына кертү һәм мөлкәт объектларына реестр номерлары кушу юлы белән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте Реестрга кертелә;

- әлеге Регламентның 1 нче кушымтасына туры килгән формада Реестрга кертүне раслау турында белдерү проекты әзерләнә һәм килештерү өчен Бүлек мөдиренә юллана.

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен нигезләр булса, Бүлек белгече әлеге Регламентның 2 нче кушымтасына туры китереп Реестрга кертүдән баш тарту турында Белдерү әзерли һәм килештерү өчен Бүлек мөдиренә юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедуралар белешмәләр кергәннән соң сигез көн эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен Реестрга кертү һәм килештерү өчен Бүлек мөдиренә юлланган Реестрга кертүне раслау турында Белдерү проекты яисә Бүлек мөдиренә юлланган Реестрга кертүдән баш тарту турында Белдерү проекты.

3.2.4.2. Бүлек мөдире Реестрга кертүне раслау турында Белдерү проектын яисә Реестрга кертүдән баш тарту турында Белдерү проектын (алга таба – гариза бирүчегә җавап проекты) карый, килештерә һәм Исәпләү, мониторинг һәм мәгълүмати хезмәттәшлек идарәсе (алга таба – Идарә) башлыгына юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: килештерелгән һәм килештерү өчен Идарә башлыгына юлланган гариза бирүчегә җавап проекты.

3.2.4.3. Идарә башлыгы гариза бирүчегә җавап проектын карап чыга һәм имза кую өчен министр урынбасарына юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: Идарә башлыгы белән килештерелгән һәм имза кую өчен министр урынбасарына юлланган гариза бирүчегә җавап проекты.

3.2.4.4. Министр урынбасары гариза бирүчегә җавап проектын карап чыга һәм имза куя, эш башкару бүлегенә регистрациягә юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: Имза куелган һәм эш башкару бүлегенә регистрациягә юлланган Реестрга кертүне раслау турында Белдерү яки Реестрга кертүдән баш тарту турында Белдерү.

3.2.4.5. Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен Реестрга кертү процедурасы әлеге Регламентның 2.9 п.да күрсәтелгән нигезләр буенча туктатылса, Бүлек белгече әлеге Регламентның 3 нче кушымтасына туры китереп Реестрга кертү процедурасын туктатып тору турында Белдерү проекты әзерли һәм килештерү өчен Бүлек мөдиренә юллый, әлеге Регламентның 3.2.4.2

- 3.2.4.4, 3.2.5.1 пунктларында күрсәтелгән процедураларның үтәлешен тәэмин итә.

Әлеге пункт билгели торган процедуралар әлеге Регламентның 3.2.3.1 пунктына туры китереп соралган белешмәләр кергәннән соң 24 көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә юлланган Реестрга кертү процедурасын туктатып тору турында Белдерү.

3.2.4.6. Дәүләт хезмәтен күрсәтү әлеге Регламентның 2.9 п.да күрсәтелгән нигезләр буенча туктатылып торса, гариза бирүче өстәмә белешмәләр тапшырганнан соң, әлеге Регламентның 3.2.4.1 - 3.2.4.4 пунктларында каралган процедуралар башкарыла.

Әлеге пункт билгели торган процедуралар гариза бирүче өстәмә белешмәләр тапшырганнан соң 25 көн эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: имзаланган һәм регистрация өчен эш башкару бүлегенә юлланган Реестрга кертү турында Белдерү.

3.2.4.7. Дәүләт хезмәтен күрсәтү туктатылып торганнан соң гариза бирүче Реестрга кертү процедурасын туктатып тору турында Белдерү юлланганнан соң 30 көн эчендә өстәмә белешмәләр тапшырмаса, Бүлек белгече әлеге Регламентның  3.2.4.1 пунктына туры китереп Реестрга кертүдән баш тарту турында Белдерү әзерли һәм әлеге Регламентның 3.2.4.2 - 3.2.4.4 пунктларында каралган процедуралар башкарыла.

Әлеге пункт билгели торган процедуралар гариза бирүчегә өстәмә белешмәләр тапшыру өчен бирелгән вакыт тәмамланганнан соң 25 көн эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: имзаланган һәм регистрация өчен эш башкару бүлегенә юлланган Реестрга кертүдән баш тарту турында Белдерү.

3.2.5. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен юллау.

3.2.5.1. Эш башкару бүлеге белгече Реестрга кертүне раслау турында Белдерү проектын яисә Реестрга кертүдән баш тарту турында Белдерү проектын региистрацияли һәм гариза бирүче күрсәткән почта адресы белән юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: регистрацияләнгән һәм гариза бирүчегә юлланган Реестрга кертүне раслау турында Белдерү яки Реестрга кертүдән баш тарту турында Белдерү.

3.3. Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрыннан мәгълүмат бирү

3.3.1. Гариза бирүчегә консультация бирү

Гариза бирүчегә консультация бирү әлеге Регламентның 3.2.1 п. туры китереп башкарыла.

3.3.2. Запросны кабул итү һәм регистрацияләү

3.3.2.1. Гариза бирүче (аның вәкиле) запросны эш башкару бүлегенә тапшыра (юллый).

3.3.2.2. Эш башкару бүлеге белгече запросны регистрацияли, керү номеры суга һәм карау өчен Бүлеккә юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура запрос кергәннән соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедураларның нәтиҗәсе: теркәлгән һәм каару өчен Бүлеккә юлланган запрос.

3.3.2.3. Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрыннан өземтә формасында Реестрдан мәгълүмат (алга таба – Реестрдан өземтә) бирү әлеге Регламентның 4 нче кушымтасына туры китереп түбәндәгеләргә бирелә:

учет объектларының хокук ияләренә яки аларның законлы вәкилләренә;

учет объектларының хокук ияләреннән яки аларның законлы вәкилләреннән ышанычнамә алган физик һәм юридик затларга;

Россия Федерациясе Хисап палатасы, Татарстан Республикасы Хисап палатасы;

Татарстан Республикасы җирле үзидарә һәм дәүләт хакимияте органнарына, Россия Федерациясенең башка субъектларына;

Дәүләт хакимиятенең федераль органнарына, шул исәптән:

Күчемсез милеккә һәм аның белән алыш-бирешкә дәүләт регистрациясе үткәрүче органнарга;

салым органнарына;

судларга, хокук саклау органнарына, учет объектлары һәм (яки) аларның хокук ияләренә бәйле эшләр булган суд пристав-башкаручыларына;

федераль антимонополиягә каршы органга һәм аның Татарстан Республикасындагы территориаль органына.

Башка затларга Реестрдан мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрында мөлкәт объектының булуы (булмавы) турында белешмә (алга таба – Реестрда булуы турында белешмә) рәвешендә әлеге Регламентның 5 нче кушымтасы формасында бирелә.

3.3.3. Ведомствоара запрослар формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашкан органнарга юллау

3.3.3.1. Бүлек белгече мәгълүматны тәгаенләү өчен ведомствоара электрон арадашлык системасы аша электрон формада түбәндәге запросларны юллый:

аерым затның үзендәге күчемсез милек объектларына хокуклары турында ЕГРНнан өземтә бирү турында ТР буенча Росреестрга;

күчемсез милеккә хокуклары күчү турында ЕГРНнан өземтә бирү турында ТР буенча Росреестрга;

Әлеге пункт билгели торган процедуралар әлеге Регламентның 3.3.2.2 п.да каралган процедура тәмамланганнан соң биш көн эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: белешмәләр (документлар) бирү турындагы запрослар.

3.3.4. Реестрдан өземтә формасында мәгълүмат яисә Реестрда мөлкәт объектларының булуы турында белешмә, Реестрдан соралган мәгълүматны бирүдән баш тарту әзерләү

3.3.4.1. Бүлек белгече әлеге Регламентның 3.3.3.1 пункты нигезендә юлланган запрослар буенча ТР буенча Росреестрдан белешмәләр алганнан соң түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

- гариза бирүчегә Реестрдан өземтә яисә Реестрда мөлкәт объектларының булуы турында белешмә бирү өчен нигезләр булуын тикшерү;

- Реестрдан өземтә проекты яисә Реестрда булуы турында белешмә проекты әзерләү һәм килештерү өчен Бүлек мөдиренә юллау;

- әлеге Регламентның 2.9 п.да күрсәтелгән очракларда Бүлек белгече соралган мәгълүматны бирүдән дәлилләнгән Баш тарту проектын (алга таба – Баш тарту) әлеге Регламентның 6 нчы кушымтасына туры китерелгән формада әзерләү һәм килештерү өчен Бүлек мөдиренә юллау.

Әлеге пункт билгели торган процедуралар белешмәләр кергәннән соң сигез көн эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: әзерләнгән һәм килештерү өчен Бүлек мөдиренә юлланган Реестрдан өземтә проекты яисә Реестрда булуы турында белешмә проекты, яисә Баш тарту проекты.

3.3.4.2. Бүлек мөдире Реестрдан өземтә проектын яисә Реестрда булу турында белешмә проектын, яисә Баш тарту проектын карый, килештерә һәм килештерү өчен идарә башлыгына юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: килештерелгән һәм килештерү өчен идарә башлыгына юлланган Реестрдан өземтә проекты яисә Реестрда булу турында белешмә проекты, яисә Баш тарту проекты.

3.3.4.3. Идарә башлыгы Реестрдан өземтә проектын яисә Реестрда булу турында белешмә проектын, яисә Баш тарту проектын карый, килештерә һәм имза өчен министр урынбасарына юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: Идарә башлыгы белән килештерелгән һәм имза өчен министр урынбасарына юлланган Реестрдан өземтә проекты яисә Реестрда булу турында белешмә проекты, яисә Баш тарту проекты.

3.3.4.4. Министр урынбасары Реестрдан өземтә проектын яисә Реестрда булу турында белешмә проектын, яисә Баш тарту проектын карый һәм имза куя, Реестрдан өземтәне регистрацияләү өчен Бүлеккә юллый яки Реестрда

булу турында белешмәне яисә Баш тартуны регистрацияләү өчен Эш башкару бүлегенә юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер көн эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: Министр урынбасары имзалаган һәм регистрацияләү өчен Бүлеккә юлланган Реестрдан өземтә, яки министр урынбасары имзалаган һәм регистрацияләү өчен Эш башкару бүлегенә юлланган Реестрда булу турында белешмә яисә Баш тарту.

3.3.5. Гариза бирүчегә Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрыннан мәгълүмат юллау, яисә Реестрдан соралган мәгълүматны бирүдән баш тартуны юллау

3.3.5.1. Эш башкару бүлеге белгече Реестрда булу турында белешмәне яисә Баш тартуны регистрацияли һәм гариза бирүче күрсәткән почта адресына юллый.

Процедура нәтиҗәсе: эш башкару бүлегендә регистрацияләнгән һәм гариза бирүчегә юлланган Реестрда булу турында белешмә яисә Баш тарту.

Әлеге пункт билгели торган процедура әлеге Регламентның 3.3.4.4 п.да күрсәтелгән процедура тәмамланганнан соң ике эш көне эчендә үтәлә.

3.3.5.2. Бүлек белгече Реестрдан өземтәне Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрыннан өземтәләрне регистрацияләү журналында регистрацияли.

Процедура нәтиҗәсе: регистрацияләнгән Реестрдан өземтә.

Әлеге пункт билгели торган процедура моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң ике эш көне эчендә үтәлә.

3.3.5.3. Реестрдан өземтәне алу өчен гариза бирүче (аның вәкиле) килгәндә Бүлек белгече түбәндәгеләрне башкара:

гариза бирүче вәкиленең шәхесен таныклаган документны, аның гариза бирүче исеменнән эш итү вәкаләтләрен (боерык, ышанычнамә) тикшерә;

- гариза бирүчегә (аның вәкиленә) Реестрдан өземтәне тапшыра һәм аны бирү турында Татарстан Республикасы дәүләт милке Реестры өземтәләрен регистрацияләү журналына язып куя.

Әлеге пункт билгели торган процедура гариза бирүче (аның вәкиле) килгән көнне үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә тапшырылган Реестрдан өземтә.

3.4. Региональ ведомствоара электрон үзара арадашлык системасы кысаларында Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрыннан мәгълүмат бирү

3.4.1. Запрос региональ ведомствоара электрон үзара арадашлык системасы аша керсә Бүлек белгече түбәндәгеләрне башкара:

- әлеге Регламентның 3.3.4.1 пунктына туры китереп Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрыннан белешмә бирү өчен нигез булу-

булмавын тикшерү һәм Реестрдан өземтә яисә Реестрда булуы турында белешмә әзерләү;

- Реестрдан өземтәне яисә Реестрда булу турында белешмәне, яисә Баш тартуны электрон формада юллау.

Процедура нәтиҗәсе: Реестрдан өземтәне яисә Реестрда булу турында белешмәне, яисә Баш тарту проектын электрон формада юллау.

Әлеге пункт билгели торган процедура Региональ ведомствоара электрон үзара арадашлык системасы кысаларында запрос кергән вакыттан башлап санаганда, биш көн эчендә гамәлгә ашырла.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләр эзлеклелеге саклануын дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Идарә (бүлек) җитәкчесе әлеге Регламент нигезләмәләрен үтәү һәм башкаруны күзәтү юлы белән контрольдә тота.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып түбәндәге тикшерүләр тора:

- хезмәт күрсәтү буенча документлар проектларына экспертизалар үткәрү. Экспертиза нәтиҗәсе булып проектларга виза салу тора;

- тиешле тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү;

Бүлектә эш башкаруны алып баруны тикшерүләр үткәрү.

Тикшерүләр планлы (Министрлыкның эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Планлы тикшерүләр үткәргәндә хезмәт күрәстүгә бәйле барлык сораулар карала (комплекслы тикшеренүләр), яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеген контрольдә тоту дәүләт хезмәте күрсәтүне оештыру эше өчен җаваплы министр урынбасары, эш башкару бүлеге белгечләре, шулай ук, Министрлыкның имәп, мониторинг һәм мәгълүмати арадашлык идарәсенең Туплау бүлеге белгечләре тарафыннан башкарыла.

4.3. Агымдагы контрольне башкаручы вазыйфаи затлар Министрлыкның структур бүлекчәләре турында нигезләмәләр, вазыйфаи регламентлар белән гамәлгә ашырыла.

Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозулар ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законы нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Регламент үтәлешен гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан контрольдә тоту Министрлыкка мөрәҗәгатьләр юллау,

шулай ук, Регламент үтәлеше барышында кылган (кылмаган) гамәлләре турында шикаятьләр белән дәүләт хакимиятенең югарырак органнарына мөрәҗәгатьләр аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең карарларына, кылган (кылмаган) гамәлләренә карата судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерү

5.1. Гариза бирүчеләр Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең карарларына, кылган (кылмаган) гамәлләренә карата шикаять белдерүгә хокуклы.

5.2. Шикаять язмача кәгазьдә яисә электрон формада Министрлыкка бирелә.

Министрның карарларына шикаять Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә

5.3. Шикаять почта аша, МФЦ аша, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып Министрлыкның рәсми сайты, Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр порталы яисә Дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул итү барышында кабул ителергә мөмкин.

5.4. Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итә ала, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирүченең запросын теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылганда;

3) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган документлар таләп иткәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылган документларны кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр баш тартуга нигезләр федераль законнар һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә күздә тотылмаса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган түләү таләп иткәндә;

7) Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы ялгыш язуларны һәм хаталарны

төзәтүдән баш тартканда яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозганда.

5.5. Шикаять түбәндәге мәгълүматлардан торырга тиеш::

1) карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә шикаять белдерелгән Министрлыкның, аның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүче физик затның фамилиясе, исеме, этисенең исеме (булганда), яшәү урыны турында мәгълүматлар, мөрәҗәгать итүче юридик затның урнашкан урыны турында мәгълүматлар, шулай ук элемтәгә керү өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) Министрлыкның, аның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре турында мәгълүматлар;

4) гариза бирүченең Министрлыкның, аның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең карары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре белән килешмәвенә дәлилләре. Гариза бирүче үз дәлилләрен раслый торган документлар (булганда) яки аларның күчермәләрен тапшыра ала.

5.6. Министрлыкка кергән шикаять шикаятьләрне карап тикшерүгә вәкаләте булган вазыйфаи зат тарафыннан шикаять теркәлгән көннән алып унбиш эш көне эчендә карап тикшерелергә тиеш, Министрлык, аның вазыйфаи заты гариза бирүчедән документларын кабул итеп алудан баш тартуга яки ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуга яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуга карата шикаять белдерелгән очракта - аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.

5.7. Министрлык шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан кабул ителгән карарны юкка чыгару рәвешендә, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда Министрлык тарафыннан җибәрелгән ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә түләтү күздә тотылмаган акча средстволарын гариза бирүчегә кире кайтарып бирү рәвешендә, шулай ук башка рәвешләрдә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

5.8. Әлеге Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгәннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача һәм, гариза бирүченең теләгенә карап, электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.9. Шикаятьләрнең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетында карап тикшерү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен
Татарстан Республикасы Дәүләт милке реестрына кертү
һәм аннан мәгълүмат бирү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына 1 нче кушыта

N ________ "__" ____________ 20__ ел.

Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрына
кертүне раслау турында белдерү

Әлеге белдерү белән ____________________________________________________________
(юридик зат атамасы)
мөлкәт объектының Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрына кертелүе раслана

Вазифа (имза) Ф.И.ӘИ.

Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен
Татарстан Республикасы Дәүләт милке реестрына кертү
һәм аннан мәгълүмат бирү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына 2 нче кушыта

N ________ "__" __________ 20__ ел.

Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрына
кертүдән баш тарту турында белдерү

Әлеге белдерү белән түбәндәгеләрне хәбәр итәбез:
__________________________________________________ Татарстан Республикасы дәүләт
(юридик зат атамасы)
милке реестрына кертүдән баш тартыла.
Сәбәпләре(кирәклесен күрсәтергә):

- мөлкәтнең Татарстан Республикасы милкендә булмавы ачыкланды;
- гариза бирүче Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрына кертү процедурасы туктатылгач билгеләнгән срокларда өстәмә белешмәләр китермәде.

Вазифа (имза) Ф.И.ӘИ.

Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен
Татарстан Республикасы Дәүләт милке реестрына кертү
һәм аннан мәгълүмат бирү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына 3 нче кушыта

N _______ "__" __________ 20__ ел.

Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрына кертүне туктатып тору турында
белдерү

Әлеге белдерү белән _______________________________________________________
(юридик зат атамасы)
Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрына кертүне туктатып тору турында хәбәр итәбез.
Процедураны туктатып тору өчен нигез булып тора:
___________________________________________________________________________.

Вазифа (имза) Ф.И.ӘИ.

Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен
Татарстан Республикасы Дәүләт милке реестрына кертү
һәм аннан мәгълүмат бирү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына 4 нче кушыта

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
“Татарстан Республикасы
Дәүләт милке реестры турында
нигезләмәне раслау турында”
2003 елның 20 мартындагы N 150
карары белән расланган

**Татарстан Республикасы дәүләт гербы**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ**

№ _____ «___»_______20__ ел

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ МИЛКЕ РЕЕСТРЫННАН**

**ӨЗЕМТӘ**

«___»________ 20__ елгы халәт буенча Татарстан Республикасы Дәүләт милке реестрында түбәндәге Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте бар:

| Реестр номеры | Хокук иясе | | Хокук төре, нигезе (номер, дата) | Реестрга кертү датасы | Объектның атамасы һәм тасвирламасы (этаж, Төзелеш материалы h.б.) | Инвентарь һәм кадастр номеры | Урнашкан урыны (адрес) | Саны | | | | салынган (алынган) елы | Беренчел-торгызылган бәясе, мең сумнарда | Калган бәясе, мең сумнарда | Калган Бәясен билгеләү датасы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Тулы атамасы | Код ОКПО | | | | | | данә яки п. метр | мәйданы (кв. метр) | | | | | | |
| | | | | | | | | | гомуми | файдалы | кушылган-өстәлгзн бүлмәләр | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | |

М.П.

(Вазифа (имза) Ф.И.ӘИ.

Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен
Татарстан Республикасы Дәүләт милке реестрына кертү
һәм аннан мәгълүмат бирү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына 5 нче кушыта

N ________ "__" _________ 20__ ел.

Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрында
мөлкәт объекты булуы (булмавы) турында
белешмәләр

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы түбәндәгене хәбәр итә: _______________________________________объекты
күчемсез милек объекты адресы күрсәтелеп, объектның атамасы)
Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрында бар/юк
(дата) (кирәкмәгәнен сызарга)

Вазифа (имза) Ф.И.ӘИ.

Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен
Татарстан Республикасы Дәүләт милке реестрына кертү
һәм аннан мәгълүмат бирү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына 6 нчы кушыта

N ________ "__" _________ 20__ ел.

Реестрдан соралган мәгълүматны бирүдән баш
тарту


Сезнең мөрәҗәгатьне (запрос) караганнан соң, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы

____________________________________________________________________________
(сәбәбе)
сәбәпле Сезнең мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән объект(лар) буенча мәгълүмат бирелә алмавын хәбәр итә

Вазифа (имза) Ф.И.ӘИ.


Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен
Татарстан Республикасы Дәүләт милке реестрына кертү
һәм аннан мәгълүмат бирү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына 7 нче кушыта

## Татарстан Республикасы дәүләт милке реестрыннан мәгълүмат бирү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы



Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен
Татарстан Республикасы Дәүләт милке реестрына кертү
һәм аннан мәгълүмат бирү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына 8 нче кушыта

**Татарстан Республикасы Дәүләт милке реестрыннан мәгълүмат бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гамәлләр эзлеклелегенең блок-схемасы**



Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен
Татарстан Республикасы Дәүләт милке реестрына кертү
һәм аннан мәгълүмат бирү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына 9 нчы кушыта

Юридик затларны һәм Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен
Татарстан Республикасы Дәүләт милке реестрына кертү
буенча дәүләт функциясен башкаруга җаваплы һәм аны күрсәтүне контрольдә тоту
өчен вазыйфаи затларның реквизитлары

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр Хамаев Азат Кыям улы | 221-40-00 | mzio@kabmin.tatarstan.ru |
| Министр урынбасары<br>Шамеев Рөстәм Илдар улы | 221-40-02 | Rustem.Shameev@tatar.ru |
| Исәпләү, мониторинг һәм мәгълүмати хезмәттәшлек идарәсе башлыгы<br>Рәхмәтуллин Илдар Рафкат улы | 221-40-42 | Ildar.Rahmatullin@tatar.ru |
| Татарстан Республикасының дәүләт милке реестры бүлеге<br>Сарыков Андрей Иванович | 221-40-50 | Andrey.Sarykov@tatar.ru |
| Канцелярия эшләрен алып бару һәм контрольдә тоту бүлеге<br>Румянцева Гөлнур Нияз кызы | 221-40-81<br>221-40-83 | Gulnur.Rumyanceva@tatar.ru |

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты**

| Адрес | Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес | Сайт |
|---|---|---|---|---|
| 420014, г. Казань, пл. Свободы, д. 1 | Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе башлыгы Нафигин<br>Альберт Илдар улы | 264-77-22 | Albert.Nafigin@ tatar.ru | www.kabmin2. tatar.ru |